ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур.,19

ИСПОЛНИТЕЛЈНЫЙ КОМИТЕ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**7 июль 2023 ел** **№ 9**

**“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны беренчел җыю урыны (урыннары) булдыру һәм аның (аларның) урнашу урыны турында кулланучыларга мәгълүмат җиткерү хакында**

“Җитештерү һәм куллану калдыклары турында” 24.06.1998 №89-ФЗ, “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 10.01.2002 №7-ФЗ, “Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 23.11.2009 № 261-ФЗ, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Җитештерү һәм куллану өлкәсендәге калдыклар белән, аларның гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә, эш итү кагыйдәләре, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләре” турында 28.12.2020, 2314 номерлы карарлары нигезендә, Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. 1. Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урам, 19 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы янында аерым торган кирпеч хуҗалык корылмасын терекөмөшле лампаларның беренчел туплану урыны итнеп билгеләргә.

2. Күп фатирлы йортларның милекчеләре, помещениеларны нанимать итеп торучылар, кулланучыларның кулланыштан чыккан терекөмешле лампаларын җыю урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү һәм куллану өлкәсендәге

калдыклар белән, аларның гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә, эш итү кагыйдәләре, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләре» турында 28.12.2020, 2314 номерлы карарының 4 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терекөмөшле лампаларны туплау урыны, шулай ук, күп фатирлы йортларда кулланыштан чыккан терекөмешле лампаларны туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмаган очракта, күпфатирлы йортларның милекчеләре, помещениеларны нанимать итеп торучылар, биналардан файдаланучылар кулланган терекөмөшле лампаларны җыю өчен дә билгеләнә.

4. 4. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә терекөмөшле лампаларны туплау җиренең урнашу урыны турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмати стендларда (стойкаларда) урнаштыру юлы белән мәгълүмат бирергә.

5. 5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгару һәм авыл җирлегендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. 6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе З.Р.Гарифуллина